ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Советская, д.22,

с. Азеево,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет урамы, 22,

Акъяр авылы,423190

тел.: (8- 84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

**КАРАР** **КАРАР**

**«21» нче ноябрь 2018 ел** **№32**

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФК нче номерлы Федераль кануны, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән «Җирле референдум турында» 23- ТРК нче номерлы Татарстан Республикасы кануны, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Акъяр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2018 нче елның 18нче ноябрендә җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән 162 нчы номерлы карарны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru., Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башлыгы** **Д.С.Гайнуллин**

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2018 елның «21» нче ноябрендәге
32 нче номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Акъяр авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.
2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 2019 нчы елның 1нче апреленә кадәр җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан чагылдырылган мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 нче группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче
гражданнардан тыш,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан башкарыла.
3. 2018 нче елның 24 нче сентябрендәге Акъяр авыл җирлеге Советының «Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында " 2018 елның 94 номерлы карары нигезендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнарның үзара салымы акчаларын түләүдән өлешчә азат итү каралмаган.

4. Нигезле сәбәпләр аркасында (авыру, озак командировкага бару, ял) бер тапкыр түләнә торган түләүләрне үз вакытында кертә алмаган түләүчеләр бер тапкыр түләнә торган түләүне кичектереп тору турында Акъяр авыл җирлеге башкарма комитетына гариза белән мөрәҗәгать итә алалар. Кичектереп түләү өч айга бирелә.
5. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгару юлы, шулай ук почта элемтәсе аша тапшыру юлы белән белән гражданнар игътибарына җиткерелә (кушымта итеп бирелә).
Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.
6. Гражданнарның үзара салымнан җыелган акчалары Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау, почта аша күчерүләрне (хисап оешмаларын) тормышка ашыру хокукына ия булган оешмалар аша,  Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша түбәндәге сылтама https://uslugi.tatarstan.ru/.буенча акча күчерү юлы белән башкарыла.

8. Түләү фактын раслаучы булып касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Гражданнарның билгеләнгән вакытка бирелмәгән үзара салым акчалары кануннарда күрсәтелгән тәртиптә түләтелә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Акъяр авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю тәртибенә кушымта

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Акъяр авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында**
**__ нче номерлы ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ)**

**Түләүче Ф. И. О.______________________________________________________**
**Адрес: _______________________________________________________________**
**________________________________нигезендә сезгә ______ срогына кадәр чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләү _______ сумны түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк:____________________________________________________________**
**Алучы банк БИК _____________________________________________________**
**Сч. № ____________________________________________________**
**Сч. Алучы. № ___________________________________________________**
**ИНН _________________________________________________________**
**КИП _________________________________________________________**
**КБК _______________ АКЫРЫНКЫ _________________________________**
**Түләүнең билгеләнеше**
**_________________________________________________________**
**Җитәкче _________________ ________________________________________**
**М. П. ________(имза) _________________(имзаны аңлату)**

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - -**
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Акъяр авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү _____ сум турында ____ нче номерлы хәбәр (хәбәрнамә)
Түләүченең ФИО _________________________________________
Адресы:_____________________________________________________________________
Алды «__» ____ 20__ ел. ____________________________________________
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Әгәр белдерү тапшырыла икән, өзек өлеше Акъяр авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*